Министерство образования и науки Республики Татарстан
ГАПОУ «Рыбно-Слободский агротехнический техникум»

Утверждаю
Директор техникума
__________ М.Г.Маннанов
«_26_» __06__ 2018 г.

**Фонд оценочных средств**
**ОУД.12 Родной язык (татарский).**
**основной профессиональной образовательной программы среднего профессионального образования**
**по специальности: 23.02.03 Техническое обслуживание и ремонт автомобильного транспорта**

2018 г.

Комплект ФОС разработан в соответствии с Федеральным государственным образовательным стандартом на основе рабочей программы, утвержденными приказом Министерства образования и науки РФ от 22 апреля 2014 года № 383.

**Организация разработчик:** ГАПОУ «Рыбно – Слободский агротехнический техникум»

**Разработчик:** Мубаракшина З.И., преподаватель

РАССМОТРЕН на заседании предметной (цикловой) комиссии общеобразовательных дисциплин
Протокол № 9 от «21» 06 2018 г.
Председатель Г.М.Альмеева

Фонд оценочных средств является частью основной профессиональной образовательной программы СПО по специальности **23.02.03 Техническое обслуживание и ремонт автомобильного транспорта**, утвержденной приказом директора ГАПОУ «Рыбно-Слободский агротехнический техникум»
от .06.2018 года №

**1.Җөмләнең башын уйлап языгыз.**

1)....,без урманга бармадык.

2)...., дустының китабын алып торды.

3)....,чөнки яз җитте.

4)....,ә ул тырыш түгел.

**2.Сүзтезмәләр төзеп языгыз.**

| | |
|---|---|
| Авылдагы | сорау |
| Шәһәрнең | туганнар |
| Кызыклы | урамнары |
| Төрки | эш |
| Җаваплы | халыклар |

**3. Татарча әйтегез.**

1) Моя подруга интересуется языками.

______________________________________________________________

2) Зимой в наших краях холодно,поэтому птиөы улетают в тёплые края.

______________________________________________________________

3) Когда закончились экзамены, мы поехали к родственникам.

______________________________________________________________

4) Казань – крупный культурный центр.

______________________________________________________________

**4. Бәхетле гаилә нинди була? Үзегезнең фикерегезне әйтегез.**

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
__________________________________________

**5) Җөмләнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.**

По-моему,он доволен своим ответом.

1)Минемчә,ул үзенең җавабыннан канәгать.

2)Минемчә, ул үзенең җавабыннан канәгать түгел.

3) Минемчә, ул аның җавабыннан канәгать.

1)Кичә мин өйдән мәктәпкә кадәр этинең машинасында бардым.

2) Мин апамның өстәлендә китапханәдән алган китапларын күрдем.

3) Алена дустының туган көненә бу бүлекне уникенче мартта ук кибеттән сатып алды.

**7)Хикәяне дәвам итеп языгыз.**

Тормышта һәр кеше югары белем алырга тиеш.

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________

**8)Җөмләләрне җөмлә кисәге ягыннан тикшерегез.**

Казан шәһәрендә Габдулла Тукай һәйкәле бар.

Болгарга ераклардан бай сәүдәгәрләр килгәннәр.

Казанда ел саен Шигырҗ бәйрәме уткәрелә.

**Вопрос 1**

Бирелгән өзек нинди стильдә язылган?

**ТР Биектау районы җирлеге үзидарә Советы урынбасары Сабитова Г.Ш. га карата чыгарылган карар белән килешмәвегез турында сезнең мөрәҗәгатегез Татарстан Республикасы президенты аппараты аша ТР прокуратурасына юлланды.**
**Варианты ответов**

- матур әдәбият стилендә
- рәсми стильдә (официально - деловой)
- фәнни стильдә (научный)

**Вопрос 2**

Түбәндәге сүзтезмәләрнең кайсысы сан сүзтезмә?

**Варианты ответов**

- соңгы җәй
- сулдан икенче
- бишлегә уку

**Вопрос 3**

Әйтү максаты ягыннан (по цели высказывания) җөмлә төрен билгеләгез: "Туган илем, Исән бул!" (Дәрдемәнд)

**Варианты ответов**

- тойгылы җөмлә (восклицательное)
- боерык җөмлә (побудительное)
- хикәя җөмлә (повеств)

**Вопрос 4**

Морфология фәне нәрсәне өйрәнә?

**Варианты ответов**

- авазлар, хәрефләр
- җөмләдәге тыныш билгеләре (знаки препинания)
- сүз төркемнәре (части речи)

**Вопрос 5**

Билгеләмәне дәвам итегез: Үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм ... (измененная чужая речь)

**Варианты ответов**

- автор сөйләме дип атала
- туры сөйләм дип атала (прямая речь)
- кыек сөйләм дип атала (косвенная речь)

**Вопрос 6**

**Булышкан** фигыле нинди заманда?
**Варианты ответов**

- үткән
- хәзерге
- киләчәк

**Вопрос 7**

Сыйфатны билгелә

**Варианты ответов**

- хәле беткән
- бирәү
- акыллы

**Вопрос 8**

Уртаклык юнәлешендәге фигыльне билгелә (совместный залог):

**Варианты ответов**

- кызлар елмаешалар
- апасы идән юдыра
- кыз юына

**Вопрос 9**

Кайсы очракта басым 1 нче иҗеккә төшә?(ударение на первый слог падает)

**Варианты ответов**

- мәктәпкә
- синме
- балаларына

**Вопрос 10**

Хикәя фигыльне билгелә: (повествоват. глагол)

**Варианты ответов**

- дус яшәргә
- укучы бала
- Казанга җиттек

**Вопрос 11**

Кайсы җөмләдә исәнлек - саулык сүзенә синоним бар?

**Варианты ответов**

- Уй- теләкләреңне, хыял- омтылышларыңны чынбарлыкка ашыру өчен нәрсә кирәк?

- Әлбәттә, сәламәт булуың.
- Сәламәтлеккә беренче адым - спорт

**Вопрос 12**

Кайсы җөмләдә **кечке** сүзенә антоним бар?
**Варианты ответов**

- Сәламәтлеккә беренче адым – спорт
- Иртәнге зарядканы ясагач, көч- куәт арта.
- Ә режим сакламау, аз хәрәкәтләнү, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәмәү яшь организмны бик тиз какшата.

**Вопрос 13**

Кайсы җөмләдә кереш сүз (вводное слово) бар?

**Варианты ответов**

- Әлбәттә, сәламәт булуың.
- Сәламәтлеккә беренче адым – спорт.
- Иртәнге зарядканы ясагач, көч- куәт арта.

**Вопрос 14**

**Уй - теләкләрне тормышка ашыру өчен тырышлык куярга кирәк.** Бу җөмләдә төшем килешендәге исемне табыгыз.
**Варианты ответов**

- тормышка
- тырышлык
- уй - теләкләрне

**Вопрос 15**

Кайсы җөмләдә тиңдәш кисәкләр (однородные члены) бар?

**Варианты ответов**

- Режим сакламау, аз хәрәкәтләнү, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәмәү яшь организмны бик тиз какшата,
- Менә шундыйларга табигать кочагында булу серләрен өйрәтәсе иде.
- Сәламәтлеккә беренче адым – спорт.

**Вопрос 16**

**Режим сакламау, аз хәрәкәтләнү, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәмәү, исерткеч эчемлекләр эчү, тәмәке тарту яшь организмны бик нык какшата.** Бу җөмләдә ничә исем фигыль (имя действия) бар?
**Варианты ответов**

- 5
- 4
- 3

**Вопрос 17**

Кайсы җөмләдә бәйлек (предлог) бар?

**Варианты ответов**

- Сәламәлек белән спорт бергә йөриләр.
- Мин һәм дусларым чаңгы шуарга яратабыз.
- Син генә спорт белән шөгыльләнергә теләмисең.

**Вопрос 18**

Теркәгечләрне (союзы)билгелә.

**Варианты ответов**

- кебек, шикелле, кадәр
- һәм, ләкин, әмма
- гына, генә, дыр, дер

**Вопрос 19**

Аваз иртемнәрен (звукоподражательные слова) билгелә.

**Варианты ответов**

- мияу, бак - бак, тып - тып
- һәм, ләкин, әмма
- уфф, фии, фу

**Вопрос 20**

Рәвешне (наречие)тап.

**Варианты ответов**

- бүген
- безнеке
- әнә

**татар теленнән йомгаклау контроль эшенә аңлатма язуы**

Тест формасындагы эш төре сайланды. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора. Беренче өлеш 15 биремне үз эченә ала . Укучылар дөрес җавапны билгеләргә тиеш.

Икенче өлештә текст буенча биремнәрне язарга тиеш. Биремнәр җавапны мөстәкыйль рәвештә формалаштыру һәм язып кую рәвешендә башкарыла.

Бу биремнәр укучыларның 10 нчы сыйныфта үткән темаларны үзләштереп алган белем-күнекмәләрне тикшерүгә нигезләнә

1 вариант

А1. Кайсы төркемдә аваз һәм хәреф саны туры килә?

1. хуҗа, җиләк, йолдыз, ирек, адым;
2. юнәлеш, шагыйрь, чокыр-чакыр, дусты;
3. яшәү, тәэсир, сәламәтлек, фәкать, мөстәкыйль;
4. койрык, мәсьәлә, шигърият, кыя.

А2. *чап-чаба; чик-чиге; ук-угы; танк-таягы* сүзләрендәге аваз үзгәрешенең төрен билгеләгез:

1. ассимиляция (аваз охшашлануы); 3) аваз йотылу;
2. аваз кыскару; 4) авазлар чиратлашу.

А3. Юлдан-юлга күчерүнең дөрес очрагын билгеләгез:

1. та-я-ныр-лык, я-шә-еш, а-за-ю, ы-шан-дыр-ган;
2. та-ян-ыр-лык, яшә-еш, аза-ю, ышан-дыр-ган;
3. тая-ныр-лык, яшә-еш, азаю, ышан-дыр-ган;
4. та-яныр-лык, яш-әеш, аз-аю, ыш-ан-дыр-ган.

А4. Җөмләдә кайсы сүз күчерелмә мәгънәдә кулланыла: Туган якта һәр тал җырлый... (С. Хәким)
1)һәр; 2) тал; 3) җырлый; 4) туган як.

А5. Казан кремле Иделдә йөзгән теплоходларга ерактан ук күренеп тора җөмләсендә кремль сүзенең лексик мәгънәсен күрсәтегез:

1) исем сүз төркеменә карый; берлек санда, өченче зат тартым кушымчасы алган, баш килештә; җөмләдә ия булып тора;

2. Россиянең борынгы зур шәһәрләрендә калкурак урынга төзелгән крепость;
3. тамыр сүз;
4. күчерелмә мәгънә.

А6. Түбәндәге мисалларда һөнәрчелек сүзләре (профессионализмнар) кергән вариантны күрсәтегез:

1. мөсафир, гыйлем, мәгълүм, дарелфөнүн, икътисад;
2. үрмәкчә, мачы, кучкар, тәбикмәк, бишбармак, алчүпрәк;
3. бораулау, факел, вахта, буровой, газүткәргеч;
4. акылдаш, марсиян, җирский, хыялстан, карбизәк.

А7. Кайсы төркемдә тамыр дөрес күрсәтелмәгән?

1. рәхмәтле (рәхмәт-); 3) кыскыч (кыс-);
2. аерылмасагыз (аер-); 4) кырмыскадай (кыр-).

А8. Ясалышы ягыннан *егерме җиде* саны нинди төргә карый'?

1) тамыр сан; 2) кушма сан; 3) парлы сан; 4) тезмә сан.

А9. Аерып бирелгән сүзнең төркемен билгеләгез: *Көн <u>искиткеч</u> матур! (М. Әмир)*

1) бәйлек сүз төркеме; 2) сыйфат сүз төркеме; 3) рәвеш сүз төркеме; 4) исем сүз төркеме

АЮ. Билгеләмәне дөрес рәвештә дәвам итегез: *Кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга, шулай ук төрле предметлар һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган*
*сүзләр....*

1. ымлыклар дип атала; 3) сыйфат дип атала;
2. теркәгеч дип атала; 4) аваз ияртемнәре дип атала.

А11. Исем фигыльне табыгыз.

1) язган китап; 2) эшли башлады; 3) әйтәсе сүз; 4) дәфтәргә язу.

А12. Ияртүче теркәгечне табыгыз.

1) гәрчә; 2) тик; 3) тагын; 4) дөрес җавап бирелмәгән.

А13. *Көмештәй, аныңча, яшьләрчә, ефәктәй* рәвешләренең төркемчәсен күрсәтегез.

1. саф рәвешләр; 3) охшату-чагыштыру рәвешләре;
2. сәбәп-максат рәвешләре; 4) күләм-чама рәвешләре.

А14. Фигыль сүз төркеменә хас төрләнеш кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?

1. килеш, тартым, сан; 3) килеш, сан, дәрәҗә;
2. юнәлеш, зат-сан, барлык - юклык, заман; 4) килеш, тартым, заман.

А15. *Шарт фигыль кушымчасын күрсәтегез:*

1) -са, -сә, -са да, -сә дә; 3) -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк;
2)-ып,-еп,-ганчы,-тәнче; . 4)-ган,-гән,-кан,-кән.

Б. Текстны укыгыз һәм биремнәрне эшләгез:

Без - биш-алты яшьләрдәге бер төркем малай - тегермән артында үрдәк оясы белән балык сөзәбез. Текә кызыл ярлар арасыннан боргаланып инеш ага. Яр астыннан сыркып кына чишмә бәреп чыга. Чишмә чыккан урында суга туенган соры ком, шома ефәк тарттырып куйган кебек, тип-тигез. Кулың белән казып чокыр ясасаң, аңа шунда ук сап-салкын су мөлдерәп тула. Тоткан балыкларыбызны шунда сала барабыз. Табыш чираттан. Бер салганда эләккәне миңа булса, аннары Заиригә, Таһирга, аннары башкага. Үрдәк оясы кем кулына керә - өлешеңә тигән көмешең. Инешнең кайбер җире тубыктан, кай урыны тездән. Әмма, тегермән тарта башласа, билгә үк җитә, агым көчәя. Без, үрдәк оясын бер читкә ташлап, лычма су булган ыштан күлмәкләребезне сыгабыз, коры урын сайлап, кояшта кызынырга ятабыз. *(Г. Сабитов).*

Биремнәр:

1.Текстка исем бирегез.
2. 3 җөмләнең сүз төркемнәрен билгеләгез.
3. 2 җөмләне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез.

## 2 вариант

А1. Кайсы төркемдә аваз һәм хәреф саны туры килә?

1. егет, эшче, мавыгучан, тар; 3) ташлык, илтифат, карандаш, камил;
2. намус, тыюлык, игълан, сөяк; 4) суыткыч, тиен, дикъкать, юл.

А2. *урам - урамнар, идән - идәннәр, эшләгән - эшләгәннәр* сүзләрендәге аваз үзгәрешенең төрен билгеләгез:

1) ассимиляция; 2) аваз кыскару; 3) аваз йотылу; 4) авазлар чиратлашу.

А3. Юлдан-юлга күчерүнең дөрес очрагын билгеләгез:

1. та-мыр, сөй-лә-де-ләр, бө-тен-е-се, яз-ын;
2. там-ыр, сө-йло-де-ләр, бөтен-е-се, яз-ын;
3. там-ыр, сөйл-әде-ләр, бөт-ен-есе, я-зын;
4. та-мыр, сөй-лә-де-ләр, бө-те-не-се, язын.

А. 4. Җөмләдә кайсы сүз күчерелмә мәгънәдә кулланыла: Кояш нәкъ аңа карап алтын нурларын коя *(Ф. Сафин).*

1)кояш; 2) нурларын; 3)коя; 4) аңа.

А5. *Авылдашлардан күп сәлам алып килдем* җөмләсендә *авылдашлардан* сүзенең лексик мәгънәсен күрсәтегез:

1. исем сүз төркеменә карый; күплек санда, чыгыш килешендә;
2. бер авылдан булган кешеләрне атый;
3. тамыр, сүз ясагыч, модаль һәм бәйләгеч кушымчалардан торган сүз;
4. җөмләдә тәмамлык булып килә.

А6. Синонимик рәтне табыгыз.

3. яшьтәш, авылдаш, классташ;
4. бару, чабу, утыру.

3) утызлап (ут-); 4) чәчәк (чәч-).

5. камилләштерү, яхшырту, тутыру;
6. яхшылык, изгелек, шәфкатьлелек;

А7. Кайсы төркемдә тамыр дөрес күрсәтелгән?

1) канатлану (канат-); 2) ябылган (ябыл-);

А8. Исем ясагыч кушымчаларны күрсәтегез:

1. -ыр, -ер, -ган, -гән, -ты, -те, -а, -ә;
2. -даш, -дәш, -гы, -ге, -лык, -лек, -ла, -лә;
3. -ның, -нең, -га, -гә, -ны, -не, -дан, -дән, -да, -дә;
4. -ым, -ем, -лар, -ләр, -быз, -без.

А9. *Бака яфрагы, мүк җиләге, песи табаны* сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы буенча ясалганнар?

1. сүзләрне кушу юлы белән;
2. сүз ясагыч кушымчалар ялгау юлы белән;
3. бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү юлы белән;
4. сүзләрнең аваз составын үзгәртү юлы белән.

АЮ. *Җөмләне дөрес итеп дәвам итегез: Җөмләдә сыйфат фигыльнең сыйфатламышы төшеп калганда...*

1. исемләшә һәм килеш, сан, тартым белән төрләнә;
2. исемләшә, ләкин килеш, сан, тартым белән төрләнми;
3. бернинди үзгәреш күзәтелми; "°;-
4. сыйфатлаша һәм сыйфат дәрәҗәләрен ала.

А11. Фигыль сүз төркеменә хас төрләнеш кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?

1. килеш, сан, юнәлеш; 3) килеш, тартым, сан;
2. юнәлеш, зат-сан, барлык - юклык, заман; 4) килеш, тартым, заман.

А12. *Таба, күрә, каршы, кадәр, чаклы, тикле, хәтле* бәйлекләре үзләреннән алда килгән сүзнең нинди килештә булуын таләп итәләр?

1) баш килештә; 2) юнәлеш килешендә; 3) чыгыш килешендә; 4) иялек килешендә.

А13. *Ерак, түбән, ары, монда* рәвешләренең төркемчәсен күрсәтегез.

1. вакыт рәвешләре; 3) урын рәвешләре;
2. сәбәп-максат рәвешләре; 4) күләм-чама рәвешләре.

А14. *Шәһәргә <u>бара торган</u> юлга җәяү генә чыктылар (Г. Гобәй)* җөмләсендә аерып бирелгән фигыльнең заманын һәм төркемчәсен ачыклагыз:

1. хәзерге заман сыйфат фигыль; 3) билгесез үткән заман хикәя фигыль;
2. хәзерге заман хикәя фигыль; 4) үткән заман сыйфат фигыль.

А15. *Җыешты* фигыленең юнәлешен дөрес билгеләгез:

1. төп юнәлештә; 3) уртаклык юнәлешендә;
2. йөкләтү юнәлешендә; 4) кайтым юнәлешендә.

Б. Текстны укыгыз һәм биремнәрне эшләгез:

Их, гармун, гармун!

Сине яшьлегендә кулына алып, уйнап карамаган, яисә сыздырып-сыздырып уйнаучыга карап моңланмаган кеше бар микән? Уйната да, җырлата да, юата да ул гармун! Татар авыллары үзенең оста гармунчылары белән дан тоткан. Бер генә мәҗлес тә, бер генә тантана да гармуннан башка узмый иде. Хәер, бүген дә бәйрәмнәрдә, сабантуйларда, авыл эшчәннәре очрашканда, туйларда гармун тавышлары еш яңгырый. "Уйнагыз, гармуннар!" бәйгесенә дә республиканың төрле районнарыннан осталар җыела.

Ә сез беләсезме: гармун сүзе каян килеп чыккан? Ул - грек сүзе. "Гармоникос" дигән сүздән гармония, аннары гармоника, гармун булып телгә кергән. Гармун - гармониканың гадиләштерелгән формасы. Музыка турындагы энциклопедик сүзлекләрдә "гармоникос"ның берничә төрле мәгънәсе китерелә: гармонияле, аһәңле, охшаш, төзек, матур. П. Черныхның 1999 елда басылып чыккан хезмәтендә гармун сүзенең рус телендә унсигезенче гасырның сиксәненче елларында кулланыла башлавы турында әйтелә. Татар телендә ул унтугызынчы гасыр урталарында барлыкка килгән булырга тиеш.

Әйдә, яшәсен гармун! Уйнасын гармун! Үткәннәрне хәтерләтеп, күңелләрне дәртләндереп сайрасын гармун! *(Мөнир Абдуллин).*

Бирем :

1.Текстка исем бирегез.

2. 2 җөмләне ң сүз төркемнәрен билгеләгез.

3. 3 җөмләне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез.

Бәяләү кретерийлары

В

**Гомуми балл – 30 балл**

27-30б.-“5” ле

19-26 б.-“4” ле

15—20б.-“3” ле

14 баллдан кимрәк - 2 ле

90-100%-“5 ле”

69-89%-“4 ле”

50-68%-“3 ле”

50% тан түбән эшкә-“2 ле”